# Документы

УДК 82-94=512.145

## ИСТӘЛЕКЛӘРДӘ – СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

***И.Г. Закирова***

*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*ilzakirova@mail.ru*

1948 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре Хәмит Ярми белән Халидә Гатина оештырган фольклор экспедициясе вакытында язып алынган истәлекләр һәм сугыш чоры бәете тәкъдим ителә. Экспедиция Татарстанның Актаныш, Калинин, Мөслим һәм Минзәлә районнары авылларында була. Экспедициядә Казан дәүләт университетының өченче курс студенты, киләчәктә тарихи романнар авторы булып танылачак Нурихан Фәттахов та катнаша.

Сугыштан соңгы экспедицияләр вакытында информантларның күбесе Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр, фронтовиклар була. Алар Бөек Ватан сугышы турында шактый гына истәлекләре белән дә уртаклашалар, үзләре катнашкан яулар, сугышчан дуслары турында сөйлиләр.

Беренче истәлек Мөхәммәтзия Вәлиев сөйләве буенча язып алынган. Мөхәммәтзия Ленинград һәм Сталинград фронтларында өч ел разведчик була, дүрт тапкыр яралана. Разведчик-ефрейторның истәлекләрендә Сталинград фронтында разведкага барган бер көн бәян ителә. Салих Шакиров Бөек Ватан сугышын гвардия капитаны дәрәҗәсендә тәмамлый, күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Байрак ордены һәм «За отвагу» медале белән бүләкләнә. Салих Шакиров разведка бүлеге командиры була, истәлекләрендә дә немец тылына тел алырга барган вакытта булган вакыйгаларны искә төшерә. Мирза Ибраһимов Украинада, Днепр буенда барган каты яулар турында сөйли. Истәлектә сугышчыларның соңгы чиккә кадәр танкларга каршы торуы, немец танкларын шартлатуы, яралanучылар турында сүз бара. Шәймәрдәнов Хәниф әсирлек фаҗигасен бәян итә.

Язмаларга төзәтмәләр кертелмәде. Бу информантларың җанлы сөйләмен тоярга да, истәлекләрдәге вакыйгаларны тулырак күзалларга да ярдәм итә. Документлар Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының «Мирасханә» Язма һәм музыкаль мирас үзеге фондында саклана (34 нче коллекция, 4 нче папка).

**Төп төшенчәләр:** истәлекләр, Бөек Ватан сугышы, фольклор экспедицияләре, Тел, әдәбият һәм тарих институты

**Сылтама ясау өчен:** Закирова И.Г. Истәлекләрдә – сугыш кайтавазы // Историческая этнология. 2021. Т. 6, № 1. С. 151–170. https://doi.org/10.22378/he.2021-6-1.151-170

Бөек Ватан сугышы тәмамлануның өченче җәендә Казаннан Тел, әдәбият һәм тарих институты фольклорчылары Хәмит Ярми белән Халидә Гатина Татарстанның Актаныш, Калинин (1959 елда таркатылган район, территориясе Актаныш һәм Мөслим районнарына бирелә), Мөслим һәм Минзәлә районнары авылларына фольклор экспедициясенә чыгалар. Экспедициядә Казан дәүләт университетының өченче курс студенты, киләчәктә тарихи романнар авторы булып танылачак Нурихан Фәттахов һәм икенче курс студенты, язучы Гариф Ахуновның булачак тормыш иптәше, Шаһидә Максудова да катнашалар. Алар 11 июньнән 14 июльгә кадәр, айдан артык вакыт эчендә, 38 авылда булып, халык белән аралашалар, фольклорның күп төрле жанрларына караган материал туплыйлар. Бу материаллар соңрак күп санлы җыентыкларда, 12 томлык «Татар халык иҗаты» академик басмасында урын алачак.

Галимнәр 43 әкият, 7518 кыска җыр, күп санлы сюжетлы җырлар, мәкаль-әйтемнәр, такмаклар һәм такмазалар, балалар һәм яшьләр уеннарына караган материал туплыйлар, хәзерге вакытта онытылып барган җыеннар турында мәгълүмат язып алалар.

Сугыштан соңгы экспедицияләр вакытында информантларның күбесе Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр, фронтовиклар була. Алар Бөек Ватан сугышы турында шактый гына истәлекләре белән дә уртаклашкан. Сүз уңаеннан, фронтовиклар истәлекләр генә түгел, халык иҗатына караган шактый материал да яздырганнар. Мәсәлән, Иске Кормаш авылында туып-үскән Насыйри Фаррахов шактый гына әкиятләр яздыра. Ул 1936 елдан сугышка кадәр шофер булып эшли, сугыш башыннан машинасы белән сугышка китә. Сугышта башта шофер, аннан соң, 1941 елда ук десант бригадасында разведчик була. Фронтта 110 Александров гвардия дивизиясендә хезмәт итә. Кавказ фронтында була. 1942 елда алты айлык разведчиклар курсын үткәч, өч мәртәбә парашют белән дошман тылына төшә. Бу десант сугышлар белән үзебезнең фронтка кушыла. 1943 елның октябрь аенда II Украина фронтында Днепрны кичеп чыкканда каты яралана. 1944 елда яраланып авылга кайта. Ул I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «За боевые заслуги», «За доблестный труд» медальләре белән бүләкләнә.

Экспедиция вакытында һәр авылда фронт узган информантлар очрап торган. Фронтовиклар истәлекләрендә үзләре катнашкан яулар, сугышчан дуслары турында сөйлиләр. Шушы районда туып үскән геройлар турында истәлекләр дә очрый. Мәсәлән, Халидә Гатина Татар Әҗбие авылында 1892 елда туган Ханнан Маликовтан үз авылларында туып үскән Баян Дәүләтов турында истәлекләр язып ала. Баян Дәүләтов Белоруссия җирендә барган каты сугышлар вакытында 19 яшендә һәлак була, Советлар Союзы герое исеме һәм Ленин ордены аңа һәлак булганнан соң

бирелә. Ханнан Маликов Баянның 10 яшьтән ятим калган авыр балачагын, хәрби хезмәт турында балачактан хыяллануы турында сөйли, аның белән бәйле вакыйгаларны искә ала.

Сугыш турында беренче истәлек Вәлиев Мөхәммәтзия сөйләве буенча язып алынган. Мөхәммәтзия Вәлиев Ленинград һәм Сталинград фронтларында өч ел разведчик булган, дүрт тапкыр яраланган. 36 яшьлек элекке разведчик-ефрейторның истәлекләрендә Сталинград фронтында разведкага барган бер көн бәян ителә. Гаярь татар егете тиз генә кирәкле карар кабул итә, үзен дә, сугышчыларын да саклый белә, беркайчан да кирәкле документларны яки телне кулга төшермичә кайтмый. Шул ук вакытта бу истәлекләр шулкадәр самими, аларда арттыру да, бизәп күрсәтү дә юк.

Сугыш турындагы истәлекләре белән уртаклашкан Такталачык авыл советы рәисе Шакиров Салих (1911 елгы, 1948 елда 37 яшьтә) Бөек Ватан сугышын гвардия капитаны дәрәҗәсендә тәмамлаган, күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Байрак ордены һәм «За отвагу» медале белән бүләкләнгән. Салих Шакиров разведка бүлеге командиры була, истәлекләрендә дә немец тылына тел алырга барган вакытта булган вакыйгаларны искә төшерә.

Сугыш турында истәлекләре белән уртаклашкан икенче кеше Чалманарат авылында колхоз счетоводы булып эшләгән Мирза Ибраһимовка сугыш беткәндә нибары 20 яшь була. Мирза Ибраһимов Украинада, Днепр буенда барган каты яулар турында сөйли. Истәлектә сугышчыларның соңгы чиккә кадәр танкларга каршы торуы, немец танкларын шартлатуы, яраланучылар турында сүз бара. Бу истәлекләрдә сугыш картинасы, яулар шулкадәр төгәл бәян ителә, алар документаль кадрлар булып күз алдына баса. Мирза Ибраһимов үзенең беренче тапкыр яралануын Һәм бүләкләнүен дә бәян итә. Сүз уңаеннан әйтеп китү урынлы булыр, экспедициядән соң дүрт ел узгач, 1952 елның ахырында булачак язучы Илфак Ибраһимов туып, әтисенең Мирзамөхәммәт дигән тулы исемен Мөхәммәт Мирза буларак татар әдәбияты тарихына кертәчәк.

Мөслим районының Сикия авылында яшәүче Шәймәрдәнов Хәниф (1948 елда 38 яшь) үзенең истәлегендә әсирлек фаҗигасен бәян итә. Рядовой Шәймәрданов авыр яраланып дошман кулына эләгә, шул көннән фашист концлагерьларында исән калу өчен көрәш башлана. Әсирләрне бер лагерьдан икенчесенә күчереп, аларны ахыр чиктә Майданек лагерына илтеп җиткерәләр. Майданек – Польша җирендәге Освенцимнан кала зурлыгы белән икенче урында торган үлем лагере була. Бу лагерьда исән калу бик сирәкләргә генә эләгә.

Экспедиция вакытында Бөек Ватан сугышына багышланган җырлар, бәетләр дә язып алына. Сугышта һәлак булган Фәйзулла Абдуллинга багышланган бәет 1941 елның сентябрь аенда Калинин районы Уразмәт авылында чыгарылган. Бәет астында берничә генә юллык искәрмә дә сакланган: «Бу чорда котырынган фашистлар Совет иленә каршы сугыша иде. Шул вакытта иптәш Абдуллин Фәйзулла дошманга каршы аяусыз көрәш

алып бара иде. Ләкин көтмәгәндә башына гранат кыйпылчыгы тиеп тормыштан югала. Иптәш Абдуллинның шушы үлгән вакытта янында бергә булган иптәшләренең сөйләве буенча бу бәет чыгарыла». Авылга килгән беренче похоронка булу, Фәйзулла Абдуллинның һәлак булган вакытында иптәшләре дә янында булу, аларның бу хакта хәбәр җибәрүләре дә бәет чыгаруга этәргеч булгандыр. 1941 елда, халык, Совет иле иң-иң дип, сугышны менә бетәр, менә сугышка киткәннәр тиз генә фашистны җиңеп кайтыр дип өмет белән яшәгәндә, сугыш башлануга килгән үлем хәбәре халыкка бик авыр тәэсир иткән, күпләр сугышның бөтен фаҗигасен шушы похоронка белән генә төшенгәннәрдер дә.

Сезнең игътибарга 1948 елда фольклор экспедициясе вакытында язып алынган, Бөек Ватан сугышы фронтовикларының истәлекләрен һәм сугыш чоры бәетен тәкъдим итәбез. Язмаларга төзәтмәләр кертелмәде. Бу информантларың җанлы сөйләмен тоярга да, истәлекләрдәге вакыйгаларны тулырак күзалларга да ярдәм итә. Документлар Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының «Мирасханә» Язма һәм музыкаль мирас үзеге фондында саклана (34 нче коллекция, 4 нче папка).

## *Сугыш истәлекләре*

### I

Мин Сталинград фронтында идем. Безгә разведкага барырга туры килде. Бу 1943 елны була инде. 23 январь көнне. Сәгать төнге 2–3 тирәсе. Безгә бирелә задача язык алып кайтырга. Без өчәү: мин – Валеев, Мещеряков, Емоглатов, алар руслар. Аларга мин старший. Пуртанк дигән рабочий поселок бар. Разведрота командиры Семепота безгә шунда барырга приказ бирә инде. Без күрешеп чыгып китәбез болар белән. Без барабыз инде тау башына, поселокка. Поселокка килеп керәбез. Җортлар тактадан нык итеп эшләнгән. Немец тавышлары ишетелми. Бер җортка килеп керәбез, бәләкәй генә җортка. Әйтергә кирәк, 16–17 яшьләрдәге бер кыз бар. Монда бер карчык, анасыдыр. Без алай-болай охран калдырмадык бит. Ә кыз минем муеннан кочаклап алды. Безнең ди, кызылармеецлар бит бу, ди кыз әнкәсенә. Сөенә бу кыз, җылый. Карчык әйтә: «Атаң кая икән?» ди. Озак та үтми бер карт кеше килеп керә. Тегеләр өчәү, без дә өчәү шул җортта. Хәзер алты кеше булдык. Мин әйтәм Мещеряковка: «Бу бабайдан сораштыр, немецлар кайда?» дим, үзем русча яхшы белмим инде. «Кая хәзер, ди карт әйтә, сезгә сүләп торырга вакыт юк, ди. Каян килдегез, шунда китегез, ди. Мин сезне җәлләп әйтәм, ди. Шушы җортта унбер немец тора, ди. Хәзер кайтып керерләр, ди. Тизрәк чыгып китегез», ди. Шул сүзгә каршы мин әйтәм: «Шуларны эзлибез бит бабай, алардан качарга килмәдек». «Юк, балакаем, чыгып китегез, барыбер әрәм буласыз бит, ди. Әнә кайталар да инде!» ди.

Вакыт әз. Уже шатырдап килеп тә керәләр, бер сүз әйтеп булмый. Кул белән генә тегеләргә мич артына керегез, дим. Үлсәм үзем генә үләрмен, бөтенебезгә берьюлы үләргә кирәкмәс. Немецлар ишекне ачып килеп

керделәр. Минем кулда автомат. Немецның гәүдәсе ишектән кереп җитмәде, мин автоматтан ата башладым. Тегеләр ни, коридор тар булу сәбәпле, артка чигә башладылыр. Минем атуым ату булды, өчебезнең тегеләрне таптап чыгып китүе булды. Хәзер Мещеряковка задание шуны бирдем: «Иптәш Мещеряков, син боларның икесенең дүкәмитен ал!» дим. Безгә башка нәрсә кирәкми. Без бик ашыктык. Без китүгә өйдәгеләр ап-ак булып калдылар. Тизрәк китәргә кирәк бит. Мещеряков документларын алды боларның. Без озакламый үзебезнең штабка кайтып киттек.

Хәзер комротага дүкәмитләрне бирдек, доложить иттек. Комрота безгә «Задача моның белән генә бетмәде, диде. Безгә, диде, тере язык тотып алып кайтырга кирәк. Бик авыр эш вакыты, ашагыз да, тагын китәрсез», диде.

Азрак тамакка капкаладык та, чыгарга әзерләндек. Монысы Трактор заводы буеннан барырга инде. «Иптәш Вәлиев, диде комрота, мин бая сезгә язык алып кайтырга дигән идем, дия. Сез алып кайта алмасагыз да, зур эш эшләдегез», дия. Ләкин безгә шундый задача: языкны ничек тә алып кайтырга. Әле без Пуртанкка барган идек, хәзер Борба дигән рабочий поселокка барабыз. Комрота безгә карта буенча күрсәтеп бирә. «Сез барасыз шунда, дия, задача дия, шунда немецлар торамы, юкмы дия, аннан соң язык алып кайтырга», дия.

Без чыгып киттек. Бер төнге сәгать 4–5 тирәләре. Ай яктысы якты ул вакытта. Кышкы төн бит. Хәзер без өчәүләп чыгып киттек. Безнең фронт туктаган җиргә килеп җиттек бер чокыр буйлап. Пулеметный рота командиры белән сөйләштек тә, үзебезнең кая китәсене белгерттек тегеңә карта буенча. Бу тирәгә атмагыз дибез, әгәр без атына башласак, уң яклап безгә ярдәм итәрсез дибез. Яр буенда әрәмәлек арасы. Ята-тора барабыз. Япанга килеп чыктык. Бер җорт шәүләсе күренә җыракта, 150–200 метрлар чамасы бар. Хәзер түш белән шуып барабыз шунда. Җортның кырына килеп җиттек. Бер аяк тавышы ишетелә. Бу җортлар икәү икән. Бер-беренең арасы 30–35 метрлар тирәсе. Шул ике арада бер часовой тора. Часовойны күрдек. Мещеряковка әйтәм, шул часовойны кулга төшерергә кирәк, дим. Мещеряков бара да, часовойның йөрәгенә кадый. Кызу канлы бит егет. Аның первый эше әле. Ә безгә язык кирәк. Бу эшне бозды. Мин тегенең янына килеп чыгам да, «Эх, эшне боздың, дим. Хәзер нишлибез, дим. Икенчене эзләргә туры килер», дим. Мещеряков әйтә, «Кире киттек», ди. Мин, юк, дим. Өйгә керәбез, мин әйтәм. Барабыз тагын. Өйгә таба бара башлаган иек, бер аяксыз инвалид килеп чыга, безнең кеше, ул коралсыз. Без тегенең белән сөйләшәбез. Шул җортның хәҗәене икән. Бу йортта немеслэр бар ди ул әйтә. «Нәрсә эшләйләр?» мин сораймын. «Алар барсы да җоклайлар әле, дия, алҗып кайттылар», дия. «Алар ничәү соң?» «14 ахрысы алар», ди ул. Без, «Кораллары кайда соң?» дибез. «Колидорда да, өйдә дә бар», ди теге.

Без решать итәбез: боларның башта коралларын кулга төшерергә, аннары үзләрен.

Колидордан алты кисәк винтовка, өй, хәзер өйгә кердек. Өйдән алдык җиде кисәк. Автомат. Әле немесләрдә күтәрелү юк. Хәзер боларның кеше саны 14 була. Корал 13 кенә, дип күңел белән уйлыймын. Давай эзләргә дим мин – кая бер корал? Командирныкы карават башында эленеп тора икән, пистолет кына. Куркыныч калмады. Мещеряковка задача бирдем. «Иптәш Меще-

ряков, сиңа 15 минут вакыт. Боларны тышка чыгарып бастыр!», ә үзем икенче өйгә киттем. Ишекне ачтым. Бер-икесе уяу яткан төсле тоела бит. Кешенең санын белмим. Барып керүем булды, автоматтан боларга җибәрдем очередь.

Вакыт әз. Бер-икесе чыгып киткән бит моның. Башкалары шунда, үле калганнар. Емоглатов чыкканын барсын кулга ала тора. Бу өйдә куркыныч калмады.

Чыксам тышка мин, бер кеше дә чыгармаган. Тегеләрнең аякарын, өсләрен киендереп ята Мещеряков, тегендә барып керсәм. Мин бер-икесенә аттым да, шунда ук тегеләр тышка чыгып бастылар. Моннан унике, теге йорттан ике чыкты болар. Хәзер боларны алып айтып китәргә кирәк бит. Без кызулык белән сизмәгәнбез, таң атып килә. Хәзер карасак – Трактор заводы тау башында. Ә анда немесләр утыра икән. Безне сизгәннәр бит, пулеметтан аталар. 150 метрлар чамасы алар. Үләсе килмәй бит, яшеренергә мәҗбүр булдык. Немесләр дә безнең белән. Тегеләрнең аякларын киендердек. Нишләргә, үзебезнең якка чыгып булмай бит. Урын безнең ышык. Үзебезнең як күренә, болар ягы күренмәй. Тракторный да күренә. Без монда көннең буена утырырга мәҗбүр булдык. Көндезге сәгать икедә җиде немес опять бу җортка кайттылар. Безне белмиләр. Элек монда торалар икән. Коралларын ташладылар болар тышка. Боларны да кулга алдык. Безнең хәзер ундүрт тә җиде – җегерме бер немес булды, ә без өч кеше. Безгә үзебезнең яктан связной килде. «Давай, дия, күпме пленный бар, алып чыгыгыз», дия. Ул кеше шулай дип әйтеп тә бетерәлмәй, шундук аңа пулә тиде, яшеренмәгән.

Хәзер көн кичкә авышты. Җан түзмәй, җөрәк ашыга. Ничек тә боларны алып кайтып тапшырасы килә. Мещеряковка әйтәм, «Иптәш Мещеряков, син, мин әйтәм, икегез монда каласыз, мин шушы тал арасыннан чыгып китәм. Ә сез минем арттан немесләрне озатыгыз. Мин чокырдан чокырга түш белән үзебезнең якка шуып китәм». Озак та үтмәй, Мещряков тегеләрне минем арттан берәмтекләп тезеп чыгарып җибәрә башлый. Әгәр чыкмасалар, атарга приказ бирәм мин аңа. Мин хәзер үзебезнең якта. Немесләр берәннәп берәннәп минем арттан чыга башладылар. Урын аулак, чокыр эче. Безнең үзебезнең яктан, нинди кешеләр микән дип карап торалар безне. Килә бер старший лейтенант: «Бу немесләрне обысковать итәргә кирәк!» ди. «Иптәш лейтинант, мин әйтәм, болар дим, обысковать ителгән, кулга да алынган. Кирәк булса, тегеннән кереп ал инде». Теге аптырады инде. «Син нинди кеше? – дип сораштырмакчы була. Ничек боларны бер үзең генә тоттың?», ди. Мин тегеңә «Вакыт юк, тизрәк үзебезнекеләргә алып кайтырга кирәк», дим.ундүрт немес минем кырга килеп җиттеләр. Күңел тынычланды. Теге яктагылары өчен дә куркыныч юк – ике иптәш анда. Җан ашыга бит. Бу 14 ен тизрәк алып кайтып китәм. Үзебезнең торган җиргә кайткан идем, безнекеләр каядыр киткәннәр. Төн караңгы. Сораштыра торгач, үзебезнең частьне таптым. Алып кайттым тегеләрне, ундүртен дә. Капитанга сдавать иттем. Мещеряков белән Емоглатов да озакламый икесе дүртне алып кайттылар. Өч немес чыкканда пуля тиеп үлгәннәр. Моннан соң миңа капитан рәхмәт белдерде. Мине штабка алып китте бу. Немесләр белән барабыз. Үзебезнең начальствога күрсәтте. Шуннан соң мине «За отвагу» медале белән наградить иттеләр. Мещеряков белән Емогла-

товка да бирделәр. Дивизия алдында генерал-майор Усенко безнең өчебезгә благодарность белдерде.

Шушы көннән соң мин һәр сугышта катнаштым. Ә 2 февраль көнне немесне Сталинградтан тәмам тар-мар итеп, җирләп куйдык. Безне ялга озаттылар.

*Вәлиев Мөхәммәтзия сөйләве буенча язылды. 36 яшьтә, элекке разведчик-ефрейтор. Дүрт мәртәбә яраланган. 1941 елның августыннан башлап фронтта булган. Ленинград һәм сталинград фронтларында өч ел разведчик булган.*

*Язып алынды 22 июнь 1948 ел. Калинин районы, Уразмәт авылы.*

*Н. Фәттахов.*

II

Без Сухая Мечетка балкасында оборонада тораек. Сталинградта немесләрнең калган вакытларында, 1943 елның гыйнварында инде бу. Сталинградка керетмәс өчен немесләр бик нык оборона тоталарые. Немесләрнең оборона хәлен һәм аларның көчләренең ныклыгын белү өчен безнең разведотрядка задача куелды тел алып кайтырга. Бер төнне барган разведка уңышлы чыкмады. Командованиенең задачасы үтәлмәде. Шул ук задачаны үтәү өчен миңа приказ бирелде. Мин разведка буенча штаб начальнигы ярдәмчесе булып эшләй идем. Үзем белән 12 сугышчыны алып немесләрнең оборонасында торган пулемет кырында торучы бер сакчыны алырга китәргә тиешбез. ««Тел» булырга тиеш инде бу. Анда бару өчен без көндездән наблдение үткәрдек. Аның хәрәкәтләрен үрәндек. Сакчыдан 20 метрларерактарак немесләрнең блиндажы барые. Күзәткән чакта бигрәк тә игътибар бирдек сакчыларның алышыну вакытына – ничә сәгатьтән соң алар алышыналар. Немесләрнең һәр ике сәгать саен алышынып торуын белдек. Күзәтү шәтиҗәләре безгә «тел» алып кайтырга мөмкинлек барлыгын күрсәтте. «Тел»не алырга иң җайлы вакыт дип смена алышыр вакыт җиткән чакны сайладык. Чөнки бу вакытта сменада торучы немес солдаты арыган була. Шулай иттереп без үзебезнң операцияне үткәрү өчен төнге сәгать икене билгеләдек. Ак халатлар кидек, кинжал һәм автоматлар белән коралландык, көндездән билгеләнеп куйган сукмаклардан немес ягына чыгып киттек. Без чыгып киткәндә төнге сәгать бер эе.

Төн айлы, якты. Шулай да, бераз кар төшкәнгә, томанланып тора. Немес часовоена барып җитәргә бер йөз метр калганның соңында, бер ышык урынга туктап. Дүртәрләп өч группага бүлендек. Бер группа туп-туры часовой кырына барырга тиеш булды. Ике группа, ике яклап часовойның ике ягыннан барып, артыннан төшәргә тиеш булды. Беренче группа часовойны тере килеш кулга алырга тиеш. Ә ике группа блиндаждагы җал итүче немесләрне блиндажы ние белән үтереп бетерергә тиеш, гранаталардан ыргытып. Монысы соңыннан булырга тиеш инде. Беренче группаның башлыгы итеп мин казах егете Чембаевны билгеләдем. Калган ике группаның берсе белән үземә алдым җитәкчелекне, ә икенчесенә Әхмәттинов дигән җегетне куйдым. Ул Башкортстаннан. 12 кешедән татардан икәү, казахтан икәү, калганнары руслар, украиннар эе. Без һәрберебез билгеләнгән вакыт буенча билгеләнгән объектка ба-

рып җиттек. Группалар арасында төнге вакытта элемтә средствосы булып кесә фонаре утын күрсәтергә тиеш иек. Аны немес күрмәскә тиеш.

Хәзер инде без барып җиттек. Беренче группаның эш башлавын көтеп торабыз. Беренче группа немес часовоена 4–5 адым калгачтын, немес часовое сискәнеп, пулеметына ябеште. Ләкин бу вакытта часовойга соң иде инде. Сугышчылар барып часовойны буып алдылар. Авызына чүпрәк тутырып, капчык кигертеп, алып та киттеләр. Немеснең эше дә бетте. Немес пулеметы сакчысыз калды. Бу безнең өчен җайлы момент тудырды. Мин үземнең группадан ике солдатны пулемет кырына барып, сменага килүче икенче немесне көтәргә куштым. Аларның берсе пулемет янында немес часовое кебек булып торырга тиеш эе, икенчесе күренмәй торырга.

Минем солдатлар как только барып җиттеләр, блиндаждан алмашка немес часовое чыгып, пулеметтан биш адымнар чамасында туктап калды. Шикләнде күрәсең, үзенчә әкрен генә нәрсәдер эндәшә башлады. Безнең солдат, немесчә белмәгәч, берни эндәшми. Шул арада минем группадагы бер солдат шуышып барып, тегенең артына төште. Аның әкрен генә барып «Хальт!» дип кычкырып җибәрүенә, немец каушап төште, кулын күтәрде. Минем солдат торды да, тегеңә ташланды. Шул арада пулемет кырында торган ике солдат та килеп җиттеләр. Немеска тын алырга да ирек бирмәенчә, авызына бияләйне тыгып, кулын артка бәйләп, тиз генә алып та сыптырдылар безнең якка. Задача болай уңышлы гына чыккачтын, үзебез дә шатландык, тагын да җөрәкләндек.

Мин хәзер ике группа белән дә блиндажга нападать итәргә карар кылдым. Блиндажга нападать итү өчен ике группаны да берләштердем. Ике солдатны пулемет кырына җибәрдем һәм пулеметны блиндажга таба хәзер тотарга куштым. Сержант Максименкога блиндаждан чыгып торган торбадан тыңларга куштым. Сержант Максименко торба кырына барып колагын салды да, миңа омлый. Аның ымлавы буенча мин дә шуышып кына барып җиттем. Тыңлыйбыз икәүләп, сүләшкән-ниткән тавыш ишетелми, гырлап җоклаган тавыш ишетелә. Гырлауларына караганда, Максименко, ике кеше булырга тиеш, ти. Мин, өч кеше булырга тиеш, тим. Мин төтен торбасыннан карамакчы булдым. Торбадан карыйм: кечкенә ут җанып тора. Бер немеснең җоклап җатканы күренә, башка берни күренми. Максименкога әйтәм, ничек кенә итеп боларны тавышсыз үтереп бетереп китәргә. Максименко әйтә, ишекне ачып, автоматтан атып бетереп китәргә кирәк, ди. Мин әйтәм, тавыш чыга, күрше блиндажлардан ишетерләр, үзебезнең артъяктан төшәрләр. Тавышсыз гына немесләрне юк итеп китү өчен Максименконы, аның кырындагы ике солдатны алып, блиндажның ишек кырына килдем. Аларга әйттем, эшнең уңышлы чыгуы минә шушыларга бәйләнгән, дип, кинжалларга күрсәттем. Алар шундук аңлап алдылар, һәрберсе кинжалларын тотып тикшереп карадылар. Блиндажга керү белән һәрберебез берәр немеска ташланырга тиешбез.

Ишекне ипләп кенә ачтык. Ут начар яктырта, күпме кеше барын болай ачык күреп булмай. Вакыт та жук. Ишекне ачу белән эчкә ташландык. Ләкин, бәхетсезлеккә каршы, дүртебезгә өч кенә немес булып чыкты. Максименко белән икебезгә берне уртаклап казарга туры килде. Шулай итеп немеснең блиндажы белән эшне бетердек. Блиндажда эленеп торган полевой сумканы,

өстәлдә яткан кәгазьләрне тиз генә алып, тышка чыктык. Тышта ул-бу җук, безне сизмәгәннәр. Пулемет кырында калган ике солдат пулеметның җозагын алып җаталар ые. Шушында шакылдау ишетелеп, күрше блиндажда сүләшкән тавышлар килә башлады. Безгә ашыгырга кирәк. Югалтусыз тизрәк штабка кайтып керергә кирәк.

Эшне сизеп алдылар немесләр. Без үзебезнең якка чыгып китә башлагач, пулеметтан ут ачтылар. Ләкин соң иде инде. Үзебезнең яшерен юлдан кайтып китәргә була ые безгә. Без инде кайтып җитәбез, дигәндә генә, мимнометтан ут ачып, Максименконы гына яраладылар. Аны иптәшләр күтәрделәр. Шул килеш кайтып җиттек штабка. Безне монда бик көткәннәр икән. Югалтусыз-нисез шундый уңышлы үткәрелгән операциягә бик шатландылар. Солдатлар, офицерлар – бар да рәхмәт укый, кулны кыса, разведчиклар гадәтенчә стопка сузалар. Максименконы медсанбатка җибәрделәр.

Без алып кайткан полевой сумканы һәм башка документларны штаб начальнигы капитан Дятельгә бирдек. Безнең алып кайткан документлар командование өчен бик кыйммәтле булып чыктылар. Җитмәсә, документларныраслау өчен безнең ике «тел» дә бар. Без алып кайткан документларның һәм «телләр»нең күрсәтүе буенча командование өчен уңышлы һөҗүмгә күчәргә мөмкинлек булды. Икенче көнне безнең чәстләр немескә каршы һөҗүмгә башладылар, немесне оборонасыннан куып алып чыгып китеп, эчкә таба кысырыкладык. Шушы уңышлы үткәргән разведка операциясе өчен минем үземә Кызыл Байрак ордены бирделәр. Калган сугышчыларның унысына орденнар, икесенә «За отвагу» медале бирделәр.

*Шакиров Салих (37 яшь) сөйләве буенча язып алынды.*
*Шакиров Салих Бөек Ватан сугышын гвардия капитаны званиесендә тәмам иткән. Хәзерге вакытта Такталачык а/с председателе, Актаныш районы.*
*Язып алынды 10 июль, 1948 ел.*
*Н. Фәттахов.*

III

Днепрның сулъягында ыек. Безгә немесне киң җиргә җәелдермәскә кирәк ие. Немес безгә таба кереп җәелергә тырыша. Шуны тоткарлап калырга кирәк ие. Без бер Украина авылында торабыз. Штабтагы посылнай взвод урнашкан йорттан безне килеп уятты. Комбатарея урнашкан йортка илттеләр. Үзебезнең взвод белән бардык. Безгә комбатарея икенче бер полкка тапшырылуыбыз турында аңлатты. Безне комбатарея белән сөйләшкәндә, аерым машиналар көтеп торае. Без, шушы машиналарга төялеп, икенче бер полкка китәргә тиешбез. Төнлә килеп төштек бу полкка. Үзебезнең расчетка тиешле пушкаларны кабул иттек. Ә таң ату белән авылдан ашыгыч чыгып та киттек.

Бездән фронт 25 километр иде. Машиналар белән передовой линиягә таң атыр алдыннан, ике километр кала, юлда, без урнашкан участоктан яраланып чыгучы сугышчыларны очраттык. Сугышчылардан фронт хәлләрен сораштырдык. Алар немесләрнең көнгә берничә мәртәбә, үзләренең калган плацдармларын киңәйтү өчен зур-зур көчләр белән һөҗүмгә килгәннәрен сөйләделәр.

Машиналар калкулык астында калдылар. Без пушкаларны тартып тауга алып менәргә тиешбез. Тау башын безнекеләр кичәге көнне генә алганнар икән. Без пушканы маскировать итеп тартып алып менеп киттек. Бу вакытта инде актыра башлаган иде. Немеснең бер батареясе безгә ата башлады. Тирәякта кукуруз басуы. Үле немес гәүдәләре, безнең сул якта ватылган пулемет ята. Әле безнекеләр трофей җыйнарга да өлгермәгәннәр. Кичә генә булган ул операция. Снәрәдләр бик якын төшә башлады. Без барыбыз да пушкадан 4–5 метр читкәрәк, кукуруз арасына кереп яттык. Бездән ерак түгел генә ярылган немес снәрәде үзебезнең иптәшне – Сталинград егетен каты яралады. Мин тиз генә бер иптәшем белән шуышып аның кырына барып аягын бәйләдем. Аны плащ-палаткага салып машинага илтеп куйдык. Бик әйбәт җегет ие, аерылышу кыен булды.

Безгә тизрәк пушканы огневой позициягә илтергә кирәк. Кукуруз сабаклары арасыннан үзебезнең пушка кырыена юнәлдек. Мин, командир орудие кырында тораем. Ул пушканы кукуруз эченә эчкәрерәк алып кереп урнаштырырга кирәк турында әйтте. Бу вакытта тәмам яктырган иде. Без бер шуышып, бер тезләнеп пушканы сөйрәп киттек, кайсысы арттан этә. Көн якты булгач бик саклык белән пушканы җайлап урнаштырырга кирәк ие. Пушканы урнаштырдык. Бу вакытта бездән уң яктан куаклык арасыннан безнең танклар наступать итә иде. Боларны без күзәтеп кенә торабыз. Безнең танклар наступлениесе уңышлы чыкмады. Немесләр нык торалар ие. Бу наступлениедән соң безнең полк командованиесе ала хәбәр – безнең участоктан танковый наступление көтелә. Безнең полк противотанковый истребительный полк булганлыктан танк һөҗүменнән куркыныч булган участокка урнаштырылган иде. Безгә бик ныклы хәзерлек белән торырга кирәклек турында комбатарея әйтеп чыкты. Расчетыбыздагы егетләр һәрберебез дә актыкка чаклы нык торырга, бер немес танкысын да җибәрмәскә сүз куештык.

Шул вакыт ерак түгел урыннан беренче немес танкысы ял урыннан (балка) күренде. Без түземсезлек белән беренче снәрәдне җибәрергә хәзер торабыз. Командир батарея беренче немес танкысына төбәп атарга приказ бирде. Беренче җибәрелгән подкалибрный снәрәд немес танкысына тиде. Танк туктады. Мин беренче мәртәбә наводчик булып аткан снәрәд ие бу. Мин бу беренче уңыштан соң, үзем эсселе-суыклы булып киттем. Тагын да ныграк җан керде. Туктаган танктан немец солдатлары төшеп тирә-якка чәчелделәр. Танктан пулемет ата башлады. Моны ничек тә бетерергә кирәк. Мин икенче снәрәд җибәрдем. Танкта ут күренде. Ут күренү белән мин, бу танк белән эш бетте дип куйдым. Монысы белән күңел тынычланды. Ләкин әле танклар күп. Аларны да җимертергә кирәк. Теләк бер генә – бер танкны да үзебезнең якка җибәрмәскә, дөмектерергә бөтенесен дә. Мин тагын бер снәрәд җибәрдем – тимәде. Танк һаман килә. Мин бөтен күңел белән танкист мине күргәндер, миңа киләдер дип уйлыйм. Ләкин немес танкысы миңа төбәп атмады. Миңа бик зур мөмкинлек туган кебек булды. Ныгытып төбәп икенче снәрәд җибәрдем, танкта ут күренде. Ут күренү белән немесләр төшеп йөгерә башладылар. Бездән бер 100–150 метрлар чамасы алда урнашкан пехота аларга каршы ут ачты. Танк белән эшне бетергәч, үземдә немеснең бу тимер җен машинасы белән көрәшергә көч барлыкны сиздем.

Орудиеның башка нумерлары да үз эшләрен җитез башкарып торалар ые. Сугыш кырын төтен, тузан каплады. Немесләр артилириясе үз танкларына нык ярдәм итә. Хәзер немеснең танклары күзгә артканнан арта күренә башлады. Шушы вакытта безнең расчетта бары өч кенә кеше калды, өч иптәш яраланды. Өченче танкка ата башладым. Беренче атудан тегенең гусеницасы өзелде. Ләкин танк пушкадан атуында дәвам итә. Шул вакытта мин бер осколочный снәрәд җибәреп калам немес пехотасына. Бу вакытта инде танклар безгә якынлашып киләләр. Кисәк кенә тәнемдә кызулык сиздем. Бик каты удар булды. Уштан яздым. Аңыма килсәм, яраланганымны сиздем. Шул вакытта минем иптәш Калащенко – украин егете – өченче танкны да тончыктырган. Мин ныгытып ушыма килгәндә безнең пехота һәм танклар наступлениегә күчкәннәр иде. Һавадан авиация ярдәм итә. Бераздан мине санчастка алып киттеләр. Санбатта полк командиры килеп минем Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнүем турында белдерде һәм рәхмәт әйтеп кулымны кысты. Ул миңа безнең гаскәрләрнең наступлениегә күчкәннән соң, немесләрне куып ике авыл алганлыкларын әйтте.

*Ибраһимов Мирза (23 яшь) сөйләве буенча язып алынды.*
*Сугышта рядовой булган. Хәзерге вакытта Чалманарат авылында*
*колхоз счетоводы булып эшли.*
*Язып алынды 13 июль, 1948 ел.*
*Н. Фәттахов.*

*Майданек лагерында*

Мин 1942 елның декабрь азагында Старая Русса шәһәре тирәсендә бик каты яраландым. Ике аяк ранен булды минем пирвай разрывной пулә белән. Уң кул ике җиреннән ранен булды. Ранен булгач, ушсыз мин 5 сәгатьләп кар өстендә ятканмын. Исемә килеп, күземне ачсам, нимесләр килеп җиткәннәр. Өч нимес солдаты килде минем кырга. Торырлык хәлдә түгел бит мин. Ике нимес солдаты таяк белән кыйный башлады. Өченчесе нәрсәдер кушты да, мине тегеләр кыйнаудан туктадылар. Шул өч ниместән соң тагын бик күп булдылар болар. Җиңелрәк ранен солдатларга күтәртеп безне каядыр алып киткәннәрен сиздем. Миннән башка да раненлар күп икән. Безне автомашинага илтеп салдылар. Шуннан соң, бер авылга туктатып, анда сыер лапасына ябып куйдылар. Бик күп кенә иек без анда. Бераз тыштан хәл монда (җылырак). Безгә бер бидрә бозлы су китереп бирделәр, аннан соң бераз туң борчак. Җиңел раненләр суны эчтеләр. Миңа хәрәкәт итәргә бер җай да юк. Аннан соң безне алып киттеләр. Китереп салдылар бер такта лапас кебек җирдә. Аның эчендә кар, бераз салам.

Азрак җөриәлгән кешеләр шул саламны тагын җылыттылар. Безнең хәлне белүче дә-нитүче дә юк әле.

Алып киттеләр моннан, тагын безне машина белән кая алып баралар, кая барабыз – без белмибез инде. Пересельный пункттан безне багунга төяделәр. Багун эче шәп-шәрә, коры идән. Салкын. Бик күп тутырдылар безне монда. Халык өстендә халык. Сине ранин дип тормыйлар анда. Кая барганны әле дә

белмибез әле без. Пуез белән Пороховага барып төштек. Пуездан төшергәч тә безне мунча керттеләр. Шунан соң госпитальгә керттеләр. Палатада безнең халык бик күп ие. Минем шунда аякны кистеләр болар. Эч китә башлады, бит гел ачыган кәбестә суы, черек бәрәңге ашаталар монда. Икенче палатага күчерделәр. Монда суык, пычрак, туендыру җук. Бөтен тәндә, өс киемендә бет, сыпырып төшерәбез.

Халык көн үлә, төн үлә монда. Үлекләрне алмыйлар, шулар белән бергә ятабыз. Безгә көненә 200 грамм опилка әпие бирәләр, 700 грамм кәбестә суы. Мин шундый хәлдә биш ай яттым. Бу вакыт эчендә минем тире белән сөяк кенә калды тәндә. Безгә анда нимесләр һәрбер кешегә нумер тактылар, фанир тактага язган. Әгәр шул нумерыңны муеныңа такмасаң, алып чыгып кыйныйлар ые уштан язганчы, җә хәлең беткәнче җаңакка чапкалыйлар. Безне моннан Эстониягә күчерделәр. Киндерхос дигән лагерьда яттык. Анда да безгә черегән кортлы сыр бирәләр 200 әр грамм һәм кычыткан суы. Агуланып кешеләр үлде шуннан.

Ноябрьдә безне Швециягә озаттылар. Мунча керттеләр баргач та. Аннан соң ике аяксызларны утын төягән кебек, берничә арбага төяп каядыр җибәрделәр. Арбаны авыр булмаган ранин солдатлар алып бара. Бер ачклыларны алдан җәяү җибәрделәр. Алар баралмай башлагач, безнең өскә атыпатып бәрәләр, әрдәнә кебек. Халык кычкырыша. Уштан язучылар да күп булды. «Китер пычак, үземне үтерәм» дип кычкыралар. Ә нимесләргә кызык – көлешәләр безгә карап. Бер километр чамасы тартып алып бардылар безне. Баракка илтеп ташладылар. Көзге салкын. Бараклар озын, тактадан. Астан да буран керә, өстән дә буран керә. Монда төрле халыклар бар лагерьда. Дөнҗадагы бер милләт тә калмаган. Катын-кызлар күп, ирләр дә, картлар, бала-чагалар да. палаталарга кешеләрне суртлап тутыралар. Кайсысына каты раниннар, кайсысына җиңелләр. Палата өч кат нардан тора. Ул нарларга утырып торып булмый, ятып кына торасың. Бер нарда бишәр кеше. Палатаның уртасыннан озын мич салынган. Аңа җату җук инде. Көненә өчәр-дүртәр мәртәбә нимесләр проверка ясыйлар. Ул килгәндә муеныңнан нумерыңны чыгарып күрсәтеп торасың инде. Нимес сине кат-кат карап китә. Әгәр ул карап йөргәндә берәрсе башын кирәк кадәрледән артыграк чыгарып торса, нимес килә дә камчы белән мич өстенә яткызып кыйнай башлай. Көненә болар бер мәртәбә 300 грамм чамасы әпи, 200–300 грамм чамасы баланда (аш) бирәләр. Я аның урынына ярты литр кипиток.

Монда бер ай яткызгач, озаттылар безне Люблинга, Пулшәгә. Мунча керттеләр, үзебездә булган киемнәрне алып бетереп, бич (весь) берсен дә калдырмаенчы, трусик белән майка бирделәр. Кышкы салкында шул көе мунчадан чыккач, кар өстендә калдырдылар. Халык бик күп чирләп үлде. Баракка илткәч тә бик күп халык кырылды. Монда да барак суык, аста-өстә юк, бөрчә күп. Бөрчәнең зарары юк дип, аны бетерү турында уйлап та карамый нимесләр. Төн җокысы җук инде ул. Без барып кергәч, безгә кадәр 48 мең иптәшләрне яндырганнар дип әйттеләр карматоридә. Безгә тәрәзәдән карматори күренеп торадырые. Морҗалары бик хәтәр, күккә тиярлек булып тора.

Мин монда бик ябыктым, үлем чигендә калдым. Безне үлчәп тораларые. 38 килограммга калганыем. Сугышка кадәр 66 кило. Киевкә килгәч коткарылып, өйгә кайтканда 64 килограмм.

Комиссия булае, чирлеләрне аерым палатага илтеп куялар. Анда кеше чыдамай, барган һәркем үлеп кенә тора, тереләй чыгучы җук. Минем арадагы иптәшләр дә шул туберклезный палатада күп кенә үлделәр. Мин сугышка кадәр бик тазаем, шуңа да үлемнән калганмындыр инде.

Үзебезнекеләр килеп коткарганда шул Майданек лагерында булдым. Кызыл Армиянең килүен нимесләр әйтмиләр, шулай да охран нимесләрдән аңлап калдык. Алар «рус килеп җитә, рус килеп җитә» дип сүләнәләр ие. Үзебезнекеләр килеп алдыннан бер көн, мин күреп тордым, безнең палата белән рәдем булган ничә йөзләп кер жуучы хатын-кызларны крематориягә алып китеп җандырдылар. Нимес шуннан соң төнлә качты. 22 (23) июньдә төнлә, 1944 елны үзебезнекеләр безне коткардылар (ослабаждать иттеләр). Шуннан соң безне туган илгә кайтардылар. Киевкә килеп төштек.

*Шәймәрдәнов Хәниф (38 яшь) сөйләве буенча язып алынды.*
*Элеккеге рядовой. Инвалид. Колхозчы. Калинин районы Сикия авылы.*
*Язып алынды 24 июнь 1948 ел.*
*Н. Фәттахов.*

*Дәүләтов Баян турында истәлек*

Ул үзе фәкыйрь семьядан. Анасыннан 2–3 яшьләрендә, атасыннан 10 яшьтә калды. 1924 елны туган. Атасы үлгәч, Анасы (үги?) кияүгә китте. моны тәрбиягә ала күрше-күлән. Мин дә инде аңа бияләе булмаганда бәяләй бирдем, башка әйбере булмаса, башканы. Ашау-эчү минеке түгел ие. Укыттык. Мин 1914 елгы империалистик сугышта катнашып, күрсәткән геройлыкларым өчен «Георгиевский крест» алдым. Шул ук сугышта мин бер аякны калдырып, инвалид булып кайттым. Баян бу хәлләр белән кызыксына ие. Ул миннән сорый ие «Ничек-ничек алдың моны?» дип. Мин әйтер ием: «Сугышлар була ул, бу азакны сугышлар гына түгел әле, суга керергә кушсалар – суга кер, утка керергә кушсалар – утка кер. Разведкалар була, дошманнарны алдан барып белешеп кайтасың, кайда алар торалар. Мин шушыларга алдым», ди торган ыем. Шуларны кызыксынып миннән сорар ые.

Минем аның белән бер яшьтә Тимершәех исемле балам бар ые. Аның белән уйнарлар ые алар. Икесенә ике мылтык ясап бирдем. Аннан берсенә берсе әйтерләр ие. Мин аларга солдат уеннары өйрәтә ием, балалар уеннары өйрәтә ием. Алар шулай берсе аклар булып, берсе кызыллар булып берсенә берсе каршы чыгалар ые. Чыгып китәләр ие пычраклар аркылы, минем малай пычракларга керми ие, ә ул керә ие. Малай бик герой була ие. Аның үгәй анасы бик каты тиргәр ие. Аның кебек вакытта аның күлмәк-ыштаннарын үземнең корткага юдырыр ием. Мин аны инде күп тәрбияләдем. Ул, тормыш авыр булуга карамастан, 7 классны бетереп, шуннан соң инде ФЗОга китә, Дербышкага. Ул 3–4 яшендә вакытта атасы белән Дербышкада торды. Шунда рус телен өйрәнде, рус телен бик яхшы сөйләр ие.

Хәзер көннәрдән бер көнне китәләр минем балалар җуага. Анда була үзәк киртә. Шул киртә эчендә бер кәзә бәрәннәп җата икән. Минем улым кайта, балалар да кайта. Шуннан минем улым Баянга сөйли «Менә без бүре баласы күрдек» дип. Бу җөрәгенә чыдый алмый «Давай китәбез!» ди. Балалар риза түгел, «Бүре ашар» диләр. Мин әйтәм: «Бар, Баян». Агачтан ясалган мылтыкны ала да китә бу. Бу мылтыкны мин ясап биргән ием балаларга. Малайлар тегенең артыннан баралар. Балалар чын бүре дип баралар инде, ә үзләре күреп, куркып кайтканнар. Бу инде агач мылтык белән герой булып бара. Шуннан барсак, кәзә бәрәннәре җата. Бу кайта. Шуннан соң инде балалар көлешәләр. Баян әйтә: «Сез бернәрсә дә булдыра алмыйсыз» ди.

Ул армиягә бик шатланып китте. Шул вакытта ул миннән сорашып, мин аңарга күчтәнәчләр биреп җибәреп, шулай итеп китте ул. Ул иркен кеше баласы түгел иде. ФЗОдан кайткач, минем төрле үнәр өйрәнәсе килә дип, минем белән төрле тәгәрмәчләр эшләргә үрәнде, шуны эшләр ие ул, үрәнер ие. Колхозга эшли ие. Мин әйтер ием: «Бу колхозга эшләгәнгә миңа хезмәт көне язалар бит» дия идем. Ә ул: «Миңа көн кирәкми, миңа үрәнү кирәк» ди ие.

Армиягә киткәч миңа хатлар язды «Шулай-шулай, мин геройлыклар күрсәттем» дип. Мин анарга җавап яза ием «Шулай яхшы эшлә, мин син кайтырга матур кызлар хәзерләп куярмын» дип. Ул сүзне бик тыңлаучан ие, ни кушсалар да, каршы әйтмәде.

ФЗОдан кайтып армиягә киткәнгә кадәр колхозда кибән кую һәм башка шуның кебек эшләрдә эшләде.

Мин үзем 1892 елны туган. 1913 елны солдатка алындым. 1914 елны сугышка киттем, ефрейтор булып. Сугыш вакытында наступление каты булгач, без бара алмадык, акуп казып яттык. Бер вакытны төннә сорыйлар «Кем разведкага бара?» дип. Кемгә булса да барырга кирәк бит инде илне сакларга. Мин китәргә булдым инде, шиста (шест) алып киттем елганың тирәнлеген үлчәргә. Күпернең эченә кереп бер салдым, ике салдым, тирәнлеген белеп булмый. Өченче салуда ата башладылар. Арттан да, алдан да аткан шикелле. Инде без артка чиктек. Иптәшләр качып бетәләр инде. Барып утырдым бер бакча буена. Мин утырган вакытта лыш-лыш килгән бер тавыш ишетелә, карасам кеше икән. Ул кеше миңа «Давай утыр, давай плен калыйк» ди. Мин әйтәм, булмый дим. Шуннан без киттек, кай якка барганбыздыр инде. Без кайта торган юлда бер раненый ята. Моннан пропуска сорыйбыз. Бу әйтә: рус халкы ди. Шуннан без моны, мылтыгын алып, җилкәгә киеп, кулга кулны тотып, бу кешене күтәреп, җилгә каршы үзебезнең юнәлеш белән кайта башладык. Кайта-кайта тагын шәүлә күренә, пытыр-пытыр килә. Кайда барырга да белмибез, ни булса булыр дип, киттек. Болар тагын үзебезнекеләр булып чыктылар. Барыбыз унике кеше бергә җыелдык. Ауруны алып кайттык үзебез белән. Елганың тирәнлеген белә алмадык.

*Актаныш районы Татар Әҗбие авылында Ханнан Маликовтан язып алынган. 1935 елдан колхозчы. II группа инвалид.*
*14 июль 1948 ел.*
*Язып алучы Халидә Гатина.*

*Фәйзулла ага бәете*

Бисмиллаһи вә билләһи, җитте Корбан гаете,
Без әйтәбез, сез тыңлагыз, Фәйзулланың бәетен.

Өйдән чыгып киткән чакта үләремне мин белдем,
Барлык халык ирке өчен сугышканда җан бирдем.

Минем үлгән хәбәремне иптәшләрем белсеннәр,
Ирек өчен көрәшкәндә корбан булды дисеннәр.

Быел чәчкән икмәкләрне кайтып ашый алмадым,
Иркен Совет илләрендә озак яши алмадым.

Кавалеристлар чабып йөри яхшы атка атланып,
Дошманнарны җиңеп, илгә кайта алмыйм шатланып.

Казармага кергән чакта мылтыгымны сөядем,
Туган-үскән илләремә кайта алмады сөягем.

Казармада торган чакта яхшы ашлар ашадым,
Гөлчәчәктәй яшьлегемне Герман явыз ашады.

Һич уйламаган чагында Герман сугыш башлады,
Су сөлеге кебек идем, башларымны ашады.

Һич туктаусыз йөзәр-меңәр йөри монда машина,
Явыз герман дошман җитте минем газиз башыма.

Дошман Герман гранат атты уң як колак янына,
Кара җирләр кызыл булды, минем аккан каныма.

Гранат тигәч, якты дөнья төтен булды күземә,
Өстемдәге киемнәрем кәфен булды үземә.

Тамакларым сусаганда, сулар эчтем елгадан,
Яшәр идем дөньяларда һич туймадым мин аннан.

Сабый чакларымда үлсәм, бу көннәрне күрмәсием,
Герман сугыш башламаса, мин вакытсыз үлмәсием.

Чабып бара, кешнәп куя, безнең Совет атлары,
Герман дигән мур кырганның калмасын затлары.

Герман дигән ач этләрнең сорамагыз хәлләрен,
Утта янсын сөякләре, эт ашасын тәннәрен.

Ядро тиеп егылгач та, сестралар килделәр,
Аһ, ярасы авыр икән, үләр мескен, диделәр.

Хәлкәйләрем авыр булды гранат килеп тигәндә,
Читен булды, дуслар килеп, аһ, Абдуллин, дигәндә.

Ядро килеп тию белән янга дуслар килделәр,
Хуш, иптәшкәй, бәхил бул, дип, миңа куллар бирделәр.

Гранат тигәч күзалларым караңгыланып китте,
Сыңар кулым өзелсә дә, уфтанмасыем бу тикле.

Яраларым җиңел булса, госпитальдә ятырыем,
Исән булсам, кайчан да бер туган илгә кайтырыем.

Герман явыз ач этләргә ачуымнан ни әйтим,
Җәмәгатем, газиз балам, калдыгыз инде ятим.

Газиз балам, сине кабат, күрәлмәдем бер генә,
Суынган кан һич елынмый, мин кайталмам мәңгегә.

Актык кабат сезгә хатлар яза алмадым инде,
Үз кулларым белән сезне үстерә алмадым инде.

Җәмәгатем, васыятем шул, җаным чыккан чагында,
Фрузияне зинһар какма, тормышларга чыксаң да.

Җәмәгатем, газиз балам калды сиңа карарга,
Шат йөз белән генә карап, йомшак эндәш аңарга.

Кыш суыкта, җәй көннәрдә эсселәргә пешермә,
Начар карап, каты эндәшеп күңелләрен төшермә.

Үзем кайтып күрә алмадым, күрешергә язмагач,
Үз кулларым белән карап үстерергә язмагач.

Ялгыз карап үстерүе авыр булыр сиңа да,
Авыр чакта эчең рәнҗеп, рәнҗемә син миңа да.

Илемә кайтып эчә алмадым салкын чишмә суларын,
Фрузиянең күрә алмадым матур зифа буфларын.

Авылдашлар, мин кайталмам, бәхил булыгыз инде,
Фатыйхагыздан ташламый, дога кылыгыз инде.

Күтәренке рух белән рәхәт гомер итегез,
Рәнҗеткән чакларым булса, зинһар гафу итегез.

Минем калган бер баламны җәтим итеп какмагыз,
Кайда гына очраса да, караңгы йөз катмагыз.

Барып керсә, каршы алыгыз ачык якты йөз белән,
Елаганда юатыгыз, тәмле татлы сүз белән.

Җәмәгатем, минем өчен бик кайгырма, боекма,
Ялгыз калдым ничек яшим диеп каты борчылма.

Ташламаслар, ярдәм кулын сиңа Туган ил сузар,
Минем кайгы озак бармас, гомерең шатлыкта узар.

Минем калган киемнәрне кирәкми дип сатмагыз,
Бәлки сагынып бер карарсыз, төсем итеп саклагыз.

Герман фашист котырынып безнең илгә ташлана,
Әнкәй сиңа васыятем шул – фатиханнан ташлама.

Җисәмәгез, җыламагыз, сызылып таңнар атканда,
Фәйзуллагыз вафат булды иртән таңнар атканда.

Минем үлгән хәбәр килгәч, бәлки үксеп җыларсыз,
Туганнарым, җәмәгатем, әнкәй, ничек чыдарсыз.

Кара туфракны кызартып акты минем каннарым,
Бәхилләшергә булмады янымда туганнарым.

Бездән калган яшь буыннар бу сугышны күрмәсен,
Телә, әнкәй, башка балаң сугышларда үлмәсен.

Әнкәй мине сагынырсың, агач яфрак ярганда,
Мине уйларсың һәм еларсың, минем өйгә барганда.

Язлар җиткәч, мине уйларсың, каз канатын какканда,
Борчылырсың, сугыш беткәч барлык кеше кайтканда.

Күпме кан-яшь түксәгез дә, мине күрә алмассыз,
Үлгән кеше артларыннан куып җитә алмассың.

Исән калган балаларың, әнкәй, кайтып җыелыр,
Шул чакларда мин булмагач, күзеңнән яшь коелыр.

Җыелышларда утырганда, бәлки мине сөйләрсез,
Өзелер шунда эчләрегез, ничек итеп түзәрсез.

Аклы ситса күлмәгемнең бизәкләре беткәндер,
Кызылармеец улым кайтыр дип, әнкәем көткәндер.

Әнкәй, пешкән ашларыңны кабат ашый алмадым,
Их, туганнар, сезнең белән бергә яши алмадым.

Мине бик тиз онытмагыз, бергә утырганнарым,
Бергә тигез, рәхәт тормыш итегез туганнарым.

Туганнарым, актык кабат күрешкән идек, хуш инде,
Сезнең белән мәңгелеккә аерылулар шул инде.

*Бәет Уразмәт авылы колхозчысы Солтанова Хәтимә тарафыннан язылган.*
*Хәзерге вакытта сигез яшьлек кызы белән тора. Ире сугышта үлгән.*
*Июль, 1948 ел.*
*Ш. Максудова язып алган.*

**Автор турында белешмә:** Закирова Илсөяр Гамил кызы – филология фәннәре докторы, баш фәнни хезмәткәр, халык иҗаты бүлеге, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраhимов исем. Тел, әдәбият hәм сәнгать институты (420111, К. Маркс ур., 12, Казан, Россия Федерациясе); ilzakirova@mail.ru

*Редакциягә керде 02.03.2021* *Кабул ителде 22.03.2021*
*Басылды 21.04.2021*

## MEMORIES ARE AN ECHO OF WAR

***I.G. Zakirova***

*G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*ilzakirova@mail.ru*

Reminiscences and a bait of the war years recorded in 1948 during a folklore expedition which was organized by scholars of the Institute of Language, Literature and History Hamid Yarmi and Khalida Gatina, are offered to readers' attention. The expedition visited Aktanyshsky, Kalininsky, Muslyumovsky and Menzelinsky districts of Tatarstan. The expedition was attended by a third-year student of Kazan State University Nurikhan Fattakhov, who later became the author of historical novels.

During the post-war expeditions, most of the informants were the Great Patriotic War veterans, front-line soldiers. They share memories of the Great Patriotic War, talk about the battles in which they participated, and about their military comrades.

The first memory was recorded based on the story of Mukhammatziya Valiev. Valiev was a scout on the Leningrad and Stalingrad fronts for three years, and was wounded four times. According to the memoirs of a corporal intelligence officer, he spent one day in reconnaissance on the Stalingrad front. Salikh Shakirov ended the Great Patriotic War with the rank of Guard Captain, for display of courage he was awarded the Order of the Red Banner and the Medal For Courage. Salikh Shakirov was the commander of the reconnaissance department and recalls the events that took place during the military campaign to the German rear. Mirza Ibragimov tells about fierce battles in Ukraine, on the banks of the Dnieper. The memoirs describe how the soldiers resisted to the last, blew up German tanks, and carried out the wounded. Khanif Shaimardanov describes the tragedy of captivity.

No edits were introduced into the texts. This gives you an opportunity to feel the live speech of the informants. The documents are kept in the funds of the Center for Written and Musical Heritage “Miraskhane” of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Tatarstan Academy of Sciences (collection No. 34, folder No. 4).

**Keywords:** reminiscences, the Great Patriotic War, folklore expeditions, the Institute of Language, Literature and History

**For citation:** Zakirova I.G. Istäleklärdä – sugysh kaytavazy [Memories are an Echo of War]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2021, vol. 6, no. 1, pp. 151–170. https://doi.org/10.22378/he.2021-6-1.151-170

**About the author:** Ilsiyar G. Zakirova, Doctor Sc. (Philology), Chief Research Fellow of the Department of Folk Art, G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Tatarstan Academy of Sciences (12 K. Marx St., Kazan 420111, Russian Federation); ilzakirova@mail.ru

*Received March 02, 2021* *Accepted for publication March 22, 2021*
*Published April 21, 2021*

## ВОСПОМИНАНИЯ – ЭХО ВОЙНЫ

***И.Г. Закирова***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*ilzakirova@mail.ru*

Вниманию читателей предлагаются воспоминания и баит военных лет, записанные в 1948 г. во время фольклорной экспедиции, организованной учеными

Института языка, литературы и истории Хамидом Ярми и Халидой Гатиной. Экспедиция посетила Актанышский, Калининский, Муслюмовский и Мензелинский районы Татарстана. В экспедиции принимал участие студент третьего курса Казанского государственного университета Нурихан Фаттахов, в будущем автор исторических романов.

Во время послевоенных экспедиций большинство информантов были участниками Великой Отечественной войны, фронтовиками. Они делятся воспоминаниями о Великой Отечественной войне, рассказывают о боях, в которых они участвовали, и о боевых друзьях.

Первое воспоминание записано по рассказу Мухамматзии Валиева. Валиев три года был разведчиком на Ленинградском и Сталинградском фронтах, четырежды был ранен. В воспоминаниях разведчика-ефрейтора рассказывается об одном дне, проведенном в разведке на Сталинградском фронте. Салих Шакиров закончил Великую Отечественную войну в звании гвардии капитана, за проявленное мужество был награжден орденом Красного Знамени и медалью «За отвагу». Салих Шакиров был командиром разведывательного отдела и вспоминает события, произошедшие во время похода в немецкий тыл. Мирза Ибрагимов рассказывает о жестоких боях в Украине, на берегу Днепра. В воспоминаниях говорится о том, как воины до последнего сопротивлялись, взрывали немецкие танки, выносили раненых. Ханиф Шаймарданов описывает трагедию плена.

Правки в тексты не вносились. Это позволяет почувствовать живую речь информантов. Документы хранятся в фондах Центра письменного и музыкального наследия «Мирасханэ» Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (коллекция № 34, папка № 4).

**Ключевые слова:** воспоминания, Великая Отечественная война, фольклорные экспедиции, Институт языка, литературы и истории

**Для цитирования:** Закирова И.Г. Истәлекләрдә – сугыш кайтавазы // Историческая этнология. 2021. Т. 6, № 1. С. 151–170. https://doi.org/10.22378/he.2021-6-1.151-170

**Сведения об авторе:** Закирова Ильсеяр Гамиловна – доктор филологических наук, главный научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. К. Маркса, 12, Казань, Российская Федерация); ilzakirova@mail.ru

*Поступила 02.03.2021* *Принята к публикации 22.03.2021*
*Опубликована 21.04.2021*